ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар, 2019 ел № 29/6

Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары һәм Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 853 санлы Карары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезнамәне 1 нче кушымтада каралган тәртиптә;

2) Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары гомуми тармак эшче һөнәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре җитәкчеләре, белгечләре һәм

хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 2 нче кушымтада каралган тәртиптә.

2. Әлеге Карарның 1 пункты белән билгеләнгән Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә билгеләнгән хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең хезмәт вазыйфалары күләме һәм квалификацияләре үзгәрешсез калган очракта, Карар нигезендә хезмәт хакы түләүгә кадәр гамәлдә булган хезмәт хакына түләү системасындагы түләүдән ким булмаска тиешлеген билгеләргә.

3. Шәһәр Советының 2018 елның 08 ноябрендәге «Физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 27/9 санлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Карарның 3 пунктында «гамәлгә керә» сүзләрен «соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләре өчен гамәлдә» дип үзгәртергә;

2) физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге эчтәлектәге 55.1 пунктын өстәргә:

«55.1. Җитәкчеләргә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр Башкарма комитет билгеләгән тәртиптә башкарыла.».

4. Шәһәр Советының 2018 елның 08 ноябрендәге «Яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәләрне раслау һәм Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 27/10 санлы Кпарарының 6 пунктында «гамәлгә керә» сүзләрен «соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләре өчен гамәлдә» дип үзгәртергә.

5. Әлеге Карарның, 2018 елның 01 декабреннән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләре өчен гамәлдә булучы 1, 2 пунктларыннан тыш, рәсми басылган көненән үз көченә керүен билгеләргә.

6. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г.Мәһдиев